МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

24.07.2025 Казан ш № 465

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына үзгәрешләр кертү турында

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтү эшен камилләштерү максатларында б о е р ы к б и р ә м:

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

Министр Э.Ә. Зарипова

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 24.07.2025 ел, №465 боерыгы белән расланды

Халыкка социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларына кертелә торган үзгәрешләр

1. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 9 мартындагы 144 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2023 елның 2 ноябрендәге 858 номерлы боерыгы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Өч яшькә кадәрге балалары булган гаиләләргә дару чаралары сатып алуга түләү билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.1 пунктының 2 пунктчасында:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирүче мәгариф оешмаларында укучыларга, фән-педагогика кадрларын әзерләү программалары буенча көндезге рәвештә белем алучы затларга һәм дини белем бирү оешмаларында укучы фән-педагогика кадрларына түләнә торган стипендия, Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалата түләүләр, шулай ук медицина күрсәткечләре буенча аларның академия отспускысында булуы чорына гражданнарның күрсәтелгән категорияләренә компенсация хакында белешмә;».

2. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2019 елның 5 ноябрендәге 920 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 06.02.2020 ел, №70, 01.06.2020 ел, №380, 09.10.2020 ел, №718, 04.05.2021 ел, №290, 17.11.2021 ел, №846, 04.04.2022 ел, №254, 08.07.2022 ел, №671, 20.01.2023 ел, №21, 02.11.2023 ел, №858, 27.06.2024 ел, №456, 06.09.2024 №618боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган 18 яше тулмаган биш һәм аннан күбрәк балалы, ата-ананың берсе яки икесе дә инвалид булган һәм (яки) балаларның берсе булса да инвалид булган гаилә әгъзаларына айлык пособие билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентында:

2.6.1 пунктының 2 пунктчасында:

өченче һәм дүртенче абзацларны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«хәрби хезмәткәрләргә, ирекле формированиеләрдә булган гражданнарга, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле федераль дәүләт хезмәтен узу каралган Россия Федерациясенең мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясенең таможня органнары һәм башка органнар хезмәткәрләренә, Россия Федерациясе Милли гвардия гаскәрләрендә хезмәт итүче һәм полициянең махсус исемнәре булган затларга акчалата түләү (акчалата тәэмин итү) күләме, шулай ук Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән даими характердагы өстәмә түләүләр һәм азык-төлек белән тәэмин итү (азык-төлек паегы урынына акчалата компенсация) (булган очракта) турында белешмә, хәрби хезмәткәрләргә, ирекле формированиеләрдә булган гражданнарга, Россия Федерациясе Эчке эшләр органнары, Россия Федерациясе Җинаять-үтәтү системасы учреждениеләре һәм органнары, Россия Федерациясе мәҗбүри үтәтү органнары, Россия Федерациясе таможня органнары, федераль куркынычсызлык хезмәте органнары, Россия Федерациясе дәүләт саклау органнары һәм Россия Федерациясе законнарында хокук саклау эшчәнлегенә бәйле федераль дәүләт хезмәтен узу каралган башка органнар хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган, Россия Федерациясе Милли гвардиясе гаскәрләрендә хезмәт итүче (хезмәт узган) һәм полициянең махсус исемнәренә ия (ия булган) затларга яисә аларның гаилә әгъзаларына Россия Федерациясе законнарында һәм Россия Федерациясе субъектларының норматив хокукый актларында каралган хәрби хәрәкәтләрдә катнашуга бәйле рәвештә гомеренә һәм сәламәтлегенә китерелгән зыянны каплау өчен бирелә торган түләүләрдән тыш;

һөнәри белем бирү оешмаларында һәм югары белем бирү мәгариф оешмаларында белем алучы затларга, фәнни һәм фәнни-педагогик кадрлар әзерләү программалары буенча көндезге формада белем алучы затларга, дини белем бирү оешмаларында белем алучы затларга стипендия күләме һәм Россия Федерациясе законнарында каралган башка акчалата түләүләр күләме турында, шулай ук күрсәтелгән категориядәге гражданнарга медицина күрсәткечләре буенча академик ялда булу чорында компенсация түләүләре турында белешмә;».